Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы

**КАРАР № 9**

Рус Әшнәге авылы 2020 елның 15 декабре

**2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсендәге 10 өлешнең 2 пункты, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 12 һәм 14-15 маддәләре, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22 маддәсендәге 8 өлешнең 2 пункты, ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Уставының 19 маддәсендәге 2 өлешнең 3 пункты һәм 70,71 маддәләре нигезендә ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРӘ**:

**1 маддә**.

1. 2021 елга ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2422,9 мең сум итеп;

2) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2422,9 мең сум итеп;

3) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 0,0 мең сум итеп.

2. 2022 елга һәм 2023 елга ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2022 елга 2445,9 мең сум, 2023 елга 2475,0 мең сум итеп;

2) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2022 елга 2445,9 мең сум итеп, шул исәптән 56,63 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар, 2023 елга 2475,0 мең сум итеп, шул исәптән 115,5 мең сум күләмендә шартлы расланган чыгымнар;

3) ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты кытлыгының иң чик күләмен 2022 елга 0,0 мең сум, 2023 елга 0,0 мең сум итеп.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 маддә.**

**1.** Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2021 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2022 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең бурыч йөкләмәләре буенча 2023 елның 1 гыйнварына булган торыш буенча эчке муниципаль бурычның югары чиген 0,0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча 0,0 мең сум күләмендә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлегенең муниципаль бурычының чик күләмен билгеләргә:

2021 елга 0,0 мең сум күләмендә;

2022 елга 0,0 мең сум күләмендә;

2023 елга 0,0 мең сум күләмендә..

**3 маддә.**

**1.** ТР Балык Бистәсе муниципаль районының Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджетында 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмен 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 маддә.**

**1.** 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан маддәләре һәм чыгымнары төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлүне 5 нче кушымта нигезендә расларга. .

**2.** ТР Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджетының 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджет чыгымнарының ведомство структурасын 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

**3.** Авыл җирлеге бюджетының ачык (гавами) норматив йөкләмәләрне үтәүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2021 елга 12,0 мең сум, 2022 елга 16,0 мең сум һәм 2023 елга 14,0 мең сум итеп расларга.

**6 маддә.**

**1.** Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә алына торган дотацияләр күләмен 2021 елга 1926,0 мең сум күләмендә, 2022 елга 1945,0 мең сум күләмендә, 2023 елга 1982,7 мең сум күләмендә расларга.

**7 маддә.**

**1.** Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан алына торган җирлекләр бюджетларының баланслылыгын тәэмин итү чараларына ярдәм итүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр күләмен 2021 елга 15,0 мең сум күләмендә, 2022 елга 17,4 мең сум күләмендә, 2023 елга 3,0 мең сум күләмендә расларга.

**8 маддә.**

**1.** Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетыннан хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тормышка ашыруга җирлекләр бюджетларына алына торган субвенцияләр күләмен 2021 елга 99,8 мең сум, 2022 елга 100,90 мең сум күләмендә, 2023 елга 105,00 мең сум күләмендә расларга.

**9 маддә.**

**1.** Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2021 елда һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмалар хезмәткәрләре санын, шулай ук аларны тоту чыгымнарын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хаклы түгел.

**10 маддә.**

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Рус Әшнәге авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**11 маддә.**

1. Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар буенча түләү өчен бирелгән 2021 елның 1 гыйнварына калган акчалары, әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2020 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмаган күләмдә 2021 елда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Рус Әшнәге авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиңдәшле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**12 маддә.**

**1.** Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

.

**13 маддә.**

1. Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Рус Әшнәге авылы, Мәктәп урамы, 9а йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Рус Әшнәге авыл җирлеге Башлыгы – Совет рәисе В.Х.Хаҗиев